КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 май г.Казань № 383

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 15 сентябрь, 1129 нчы; 2024 ел, 3 апрель, 223 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 31 май, 383 нче
карары редакциясендә)

# «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

## «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә стратегик өстенлекләр

### I. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә агымдагы хәлне бәяләү

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программасы) Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте (алга таба – дәүләт мөлкәте) белән идарә итүнең максималь нәтиҗәлелеген, аның керемлелеген һәм сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелде.

Узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап, Татарстан Республикасында җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләрен үстерү берничә тарихи әһәмиятле этап (дәүләт милкен массакүләм хосусыйлаштыруны, базар мөнәсәбәтләрен һәм инфраструктураны, җир һәм муниципаль реформаларны кертеп) аша узды. Хәзерге вакытта дәүләт мөлкәте белән идарә итү түбәндәге үзенчәлекләр белән характерлана:

мөлкәт белән эш иткәндә базар алымнарын куллану;

махсус икътисадый зоналар, технопарклар һәм концессияләр кебек эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү формаларын үстерү;

масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда катнашу;

милекнең шактый күләмен гавами хакимиятнең федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәләр арасында яңадан бүлү;

учреждениеләрнең мөлкәт комплексын оптимальләштерү, файдаланылмый торган мөлкәтне ачыклау һәм аларны әйләнешкә кертү;

җир асты байлыкларын чыгару тармакларын һәм эшмәкәрлекне үстерү өчен җир кишәрлекләре категориясен үзгәртү;

Татарстан Республикасында территориаль планлаштыруны үстерүдә катнашу;

«Пространство мәгълүматлары илкүләм системасы» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында чаралар оештыру;

тармакны цифрлы трансформацияләү, шул исәптән дәүләт хезмәтләре күрсәтүне цифрлаштыру;

дәүләт мөлкәте белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлекнең норматив базасын үстерү һәм җентекле регламентацияләү;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә методологик ярдәм күрсәтүне көчәйтү.

Дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү, мөлкәттән файдалануны контрольдә тотуны көчәйтү, аның керемлелеген арттыру мәсьәләләре актуаль булып кала.

2024 ел башына Татарстан Республикасының дәүләт активлары 552,02 млрд.сум тәшкил итте, шул исәптән дәүләт учреждениеләренең оператив идарәсендәге мөлкәт кыйммәте – 142,25 млрд.сум, дәүләт унитар предприятиеләренең хуҗалык карамагындагы мөлкәт кыйммәте – 7,15 млрд.сум, номиналь кыйммәт буенча акцияләрнең (өлешләрнең) дәүләт портфеле кыйммәте – 174,13 млрд.сум, казна объектлары кыйммәте – 72,65 млрд.сум, Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренең кадастр кыйммәте – 155,84 млрд.сум.

2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы территориясендә җирләрнең гомуми мәйданы 6,78 млн.гектар тәшкил итте, шуларның 3,27 млн.гектар җире (48,2 проценты) хосусый милектә һәм юридик затлар милкендә.

Җир кишәрлекләре белән эш итү хокукы түбәндәге рәвештә бүленә:

федераль хакимият органнарының эш итү хокукы – 1,52 млн.гектар;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең эш итү хокукы – 1,94 млн.гектар;

Татарстан Республикасының эш итү хокукы – 0,05 млн.гектар.

2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында 891 юридик зат исәпләнә, шул исәптән устав капиталында дәүләт өлеше белән 803 дәүләт учреждениесе, 10 дәүләт унитар предприятиесе, 78 хуҗалык җәмгыяте бар.

2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы милкендә 71 акционерлык җәмгыяте акциясе бар, шул исәптән дәүләт өлеше булмаган 12 җәмгыятьтә махсус хокук («алтын акция») кулланыла.

2027 елга дәүләт унитар предприятиеләре санын 2 берәмлеккә кадәр киметү планлаштырыла, шуның белән бәйле рәвештә «Финанс-хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең гомуми санында Татарстан Республикасының зарарлы дәүләт унитар предприятиеләре өлеше» Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткеченең чик зурлыгын 50 процентка кадәр арттыру көтелә.

2023 елда дәүләт мөлкәтен файдаланудан һәм сатудан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре 8,11 млрд.сум тәшкил итте.

Хәзерге вакытта автоном һәм бюджет учреждениеләренә оператив идарә итү хокукы кысаларында мөлкәт белән эш итү вәкаләтләре зур күләмдә бирелде.

Шул ук вакытта автоном һәм бюджет учреждениеләренә карата идарә органнарында (милекче, күзәтү советы, гамәлгә куючы) алар белән идарә итү өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлеше законнар нигезендә саклана. Бу дәүләт бурычларын билгеләү, закон белән билгеләнгән алыш-бирешләр ясауны килештерү, шулай ук учреждениеләргә беркетелгән күчемсез мөлкәтне һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне карап тоту чыгымнарын исәпкә алып, бурычларның үтәлешен финанс белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) тарафыннан дәүләт мөлкәтеннән файдалану законлылыгын, нәтиҗәлелеген һәм максатчан файдалануны системалы контрольдә тотуны гамәлгә кертте. 2023 елда ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгы тарафыннан учреждениеләргә оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт мөлкәтеннән файдалануга һәм учреждениеләргә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән җир кишәрлекләреннән файдалануга 93 тикшерү уздырылды.

Күчемсез мөлкәтне инвентаризацияләүгә карата гомуми таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәтне инвентаризацияләүне уздыру һәм аны хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 12 март, 225 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәтне инвентаризацияләүне уздыру һәм аны хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү тәртибе билгеләнде.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына югарыда күрсәтеп үтелгән Тәртипкә таянып эш итәргә, муниципаль милекне инвентаризацияләү нәтиҗәләрен гомумиләштерергә, файдаланмау сәбәпләрен күрсәтеп, файдаланылмый торган күчемсез мөлкәт объектлары исемлеген расларга, төркемнәргә бүләргә һәм хисап елының 10 декабренә кадәр инвентаризация нәтиҗәләрен ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгына җибәрергә тәкъдим ителде.

Дәүләт мөлкәтен нәтиҗәле файдалану максатында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгы тарафыннан концессия килешүләре механизмыннан файдалану кысаларында дәүләт күчемсез мөлкәт объектларына инвестицияләр җәлеп итү буенча эш алып барыла.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү – дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарының кече һәм урта бизнесны үстерү буенча эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе.

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага, шул исәптән ташламалы шартларда бирү өчен дәүләт мөлкәте исемлеген раслау карала.

Кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү өлешендә Татарстан Республикасы дәүләт программасы бурычлары:

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегендә дәүләт мөлкәте санын арттыру;

мөлкәтне арендага бирүнең ташламалы тәртибен камилләштерү;

мөлкәтне биләүгә (файдалануга) бирү процедураларының үтә күренмәлелеген гадиләштерү һәм арттыру.

2023 елда ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан казна мөлкәтенә карата 35 аукцион, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен 23 аукцион оештырылды.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнарына элек исәпкә алынган күчемсез мөлкәт объектларының

хокук ияләрен ачыклау, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (218-ФЗ номерлы Закон) нигезендә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен күчемсез мөлкәт объектларының хокук ияләре турында белешмәләр җибәрү вәкаләтләре һәм йөкләмәләре бирелде.

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бәяләве буенча 2022 елның 1 мартына Татарстан Республикасы территориясендә хокук ияләре булмаган 847 меңнән артык күчемсез мөлкәт объекты исәпләнә, шуларның якынча 700 мең күчемсез мөлкәт объекты 218-ФЗ номерлы Законның гамәле потенциаль рәвештә кагыла (белешмә өчен: әгәр күчемсез мөлкәт объектына хокук билгеләү документлары яки әлеге күчемсез мөлкәт объектына хокукны раслый торган документлар «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр (1998 елның 31 гыйнварына кадәр) рәсмиләштерелгән һәм әлеге хокуклар Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса, 218-ФЗ номерлы Законның гамәле күчемсез мөлкәт объектларына кагыла).

2022 елның 1 марты – 2024 елның 3 гыйнвары чоры өчен 218-ФЗ номерлы Закон кысаларында 135 629 объект буенча Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә хокук ияләре турында белешмәләр кертелде, 231 076 объект буенча элек барлыкка килгән хокук теркәүгә алынды һәм башка чаралар уздырылды, 277 670 объект кадастр исәбеннән алынды.

218-ФЗ номерлы Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына методик, оештыру һәм гамәли ярдәм күрсәтү буенча чаралар күрелә. Татарстан Республикасының һәр муниципаль берәмлегендә даими нигездә ярдәм күрсәтү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән җаваплы затлар билгеләнде.

Татарстан Республикасында җир кишәрлекләрен булдыру һәм аларны күпбалалы гаиләләргә бирү эше дәвам итә. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча 2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында барлыгы 78,18 меңнән артык күпбалалы гаилә исәпләнә, шулардан 72,01 меңнән артык гаилә җир кишәрлеге алу исемлегенә кертелде.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә, күпбалалы гражданнарга җир кишәрлекләре бирү процессын оештыру эше алып барыла. Нәтиҗәдә 47,41 меңнән артык күпбалалы гаилә җир кишәрлекләрен милеккә алды.

Республиканың берничә районында җир кишәрлекләре бирү эше өстәмә җир кишәрлекләрен эзләүгә бәйле рәвештә туктатып торылды. Җир кишәрлекләренә шактый кытлык бар, аларны Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләренең күпбалалы

гаиләләренә бүлеп бирү мәсьәләсе кискен тора. Күпбалалы гаиләләр өчен өстәмә җир кишәрлекләре булдыру эшләрен үткәрүне финанслау мәсьәләсе актуаль булып кала.

Хәзерге вакытта, югарыда бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Хисап елы башына җир кишәрлеген түләүсез бирү өчен исәпкә баскан Татарстан Республикасы күпбалалы гаиләләренең гомуми санында Җир кишәрлекләрен түләүсез алган Татарстан Республикасы күпбалалы гаиләләре өлеше» күрсәткече зурлыгын арттыру буенча динамика юк.

ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе милкендәге җир кишәрлекләренә карата «ДОМ.РФ» акционерлык җәмгыяте белән хезмәттәшлек гамәлгә ашырыла.

Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын тәэмин итү әлеге категориядәге гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү чараларының аерылгысыз өлеше булып тора һәм республика җитәкчелегенең, кызыксынучы министрлыкларның, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының аерым контролендә тора.

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләре үтәлешен контрольдә тоту түбәндәгеләргә йөкләнде:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы – ятим балалар белән эшләү, аларны торак урыннары белән тәэмин итү буенча;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы – ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак фонды булдыру һәм аның белән идарә итү.

2013 – 2023 еллар чоры өчен ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы милкенә 4 725 торак урын сатып алынды. Әлеге бүлмәләр Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фонды составына кертелде һәм ятим балаларга наем шартнамәләре буенча бирелде.

Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруга каралган акчалардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру өчен чаралар исемлегенә төзәтмәләр кертелә, Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле инструментлар җыелмасы камилләштерелә, нәтиҗәсез чаралар төшереп калдырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы үтәлешенең максатчан күрсәткече – Татарстан Республикасы дәүләт программасындагы барлык күрсәткечләрнең чик зурлыкларына фактта ирешү.

Татарстан Республикасы дәүләт программасын финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## II. Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте өстенлекләре һәм максатлары тасвирламасы

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең һәм бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның стратегик өстенлекләре түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы бюджетына керемнәр керүләрне нәтиҗәле файдалану һәм максимизацияләү нигез буларак дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең сыйфатын яхшырту;

гражданнарга, эшмәкәрләргә һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру;

Татарстан Республикасында җирдән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру һәм территориаль планлаштыру сыйфатын яхшырту;

гражданнарга социаль ярдәмнең кайбер чараларын гамәлгә ашыруда катнашу;

эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасында муниципаль мөлкәт белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру.

Дәүләт мөлкәте белән идарә итү сыйфатын яхшырту һәм аннан файдаланудан алынган керемнәрне максимизацияләү түбәндәгеләр исәбеннән гамәлгә ашырылачак:

дәүләт мөлкәтен исәпкә алу һәм аның белән идарә итү процессларын цифрлы трансформацияләү;

күчемсез мөлкәтнең оптималь составын формалаштыру;

дәүләт катнашындагы компанияләр белән идарә итүдән керемнәрнең һәм активлар бәясенең озак сроклы тотрыклы үсешен тәэмин итү;

дәүләт хезмәткәрләренең квалификациясен һәм һөнәри дәрәҗәсен күтәрү.

Гражданнарга, эшмәкәрләргә һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләренең сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру түбәндәгеләр исәбеннән башкарылачак:

дәүләт хезмәтләре күрсәтү процессын цифрлаштыру;

җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә эшләүче дәүләт хакимияте органнары һәм оешмалар эшчәнлегендә клиентларга игътибарлы булудәрәҗәсен арттыру.

Татарстан Республикасында җирдән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру һәм территориаль планлаштыру сыйфатын яхшырту түбәндәгеләр исәбеннән гамәлгә ашырылачак:

җирләрне сыйфатлы дәүләт кадастр бәяләвен оештыруны гамәлгә ашыру;

күчемсез мөлкәт объектлары һәм барлык милек рәвешләрендәге җир кишәрлекләре турында җитеп бетми торган белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә территориаль планлаштыру документларына мониторинг ясау һәм аларны әзерләү буенча һәм методик кулланма.

Гражданнарга социаль ярдәмнең кайбер чараларын гамәлгә ашыруда катнашу түбәндәге юл белән гамәлгә ашырылачак:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен бирүне, шулай ук Татарстан Республикасы карамагындагы җирләрдән җир кишәрлекләре бирүне мониторинглау;

ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга торак урыннар бирү;

торак пунктларын киңәйтү, торак төзелешен үстерү максатларында җир кишәрлекләре категориясен үзгәртү өчен боеру характерындагы актлар проектларын әзерләү.

Эшкуарлыкка ярдәм итүдә катнашу түбәндәге юл белән гамәлгә ашырылачак:

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына күчемсез мөлкәт объектларын ташламалы шартларда бирү;

дәүләт мөлкәтен бирүнең төрле рәвешләрен үстерү: аренда, концессия, ышанычлы идарә;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларының рәсми сорауларын өстенлекле тәртиптә үтәү.

Татарстан Республикасында муниципаль мөлкәт белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру түбәндәге юл белән гамәлгә ашырылачак:

Татарстан Республикасының муниципаль мөлкәтен исәпкә алу һәм аның белән идарә итү процессларын цифрлы трансформацияләү;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә укыту семинарлары, стажировкалар уздыру, методик тәкъдимнамәләр җибәрү, муниципаль мөлкәт белән идарә итү палаталары, идарәләре, комитетлары эшчәнлеген мониторинглау блы белән, шул исәптән күчмә чаралар барышында, системалы һәм һәрьяклап методик ярдәм күрсәтү.

Татарстан Республикасы икътисады очраша торган актуаль проблемаларны бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегик максатларына һәм бурычларына ирешү, шул исәптән «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә (алга таба - Стратегия-2030) билгеләнгән максатларга һәм бурычларга ирешү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт программасы максаты, структурасы һәм аның күрсәткечләр системасы эшләнде.

Максат: дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең, аның керемлелеге һәм сакланышының максималь нәтиҗәлелеген тәэмин итү, ул түбәндәге күрсәткечләргә ирешү белән характерлана:

дәүләт мөлкәтен реализацияләүдән һәм алардан файдаланудан керемнәр өлешендә бюджет биремен ел саен 100 процент үтәү;

Татарстан Республикасының хисап елы башына җир кишәрлеген түләүсез бирү өчен исәпкә баскан күпбалалы гаиләләренең гомуми санында 2027 елга Татарстан Республикасының җир кишәрлекләрен түләүсез алган күпбалалы гаиләләре өлешен кимендә 67 процент тәэмин итү;

2027 елга кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән дәүләт мөлкәте исемлегенә 129 объектны кертү;

2027 елга муниципаль милек хокукына ия дип танылган, файдаланылмый торган җир өлешләренең өлешен кимендә 70,8 процент тәэмин итү.

## III. Стратегик өстенлекләр, илкүләм максатлар һәм Стратегия-2030 максатлары, Россия Федерациясе дәүләт программалары күрсәткечләре белән үзара бәйләнеш турында белешмәләр

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең стратегик өстенлекләре Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм

2036 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы белән билгеләнгән 2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең түбәндәге милли максатларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән:

тотрыклы һәм динамикалы икътисад;

тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит.

Дәүләт мөлкәтенә идарә итүнең стратегик өстенлекләре Стратегия-2030 белән билгеләнгән түбәндәге стратегик максатларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән:

дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт белән идарә итү буенча югары квалификацияле белгечләр рәвешендә Татарстан Республикасының кеше капиталын туплау;

балансллы территориаль-пространство үсеше;

җир ресурсларыннан файдалануның югары нәтиҗәлелеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасында дәүләт, хосусый һәм дәүләт-хосусый институтларның балансллы системасын булдыру, конкурентлыкка сәләтле кластерларны, эшкуарлыкны (кече һәм урта бизнесны), эчке территориаль үсешне тотрыклы үстерү.

## IV. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт идарәсе бурычлары, аларны нәтиҗәле хәл итү ысуллары

«Дәүләт мөлкәте, аның керемлелеге һәм сакланышы белән идарә итүнең максималь нәтиҗәлелеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының үзәк аппараты эшчәнлеген тәэмин итү;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү;

комплекслы кадастр эшләрен уздыру чараларын гамәлгә ашыру;

җир төзелеше эшләрен оештыру һәм тәэмин итү;

дәүләт мөлкәте белән идарә итү чараларын үткәрүне тәэмин итү.

# «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы паспорты

## 1. Төп нигезләмәләр

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт программасы кураторы | Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасының җаваплы башкаручысы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру чоры | I этап: 2014 – 2023 еллар;<br>II этап: 2024 – 2027 еллар |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасы максаты | Дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең, аның керемлелеген һәм сакланышын максималь нәтиҗәлелеген тәэмин итү |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруның бөтен чорында финанс белән тәэмин ителеш күләмнәре | I этап: 18 410 184,58 мең сум;<br>II этап: 1 665 145,3 мең сум; |
| Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәрге перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указында (алга таба – РФ Президентының 309 номерлы Указы) билгеләнгән Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе (алга таба – Стратегия-2030), Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары белән бәйләнеш | Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешүгә юнәлдереләчәк:<br>1) Россия Федерациясе Президентының 309 номерлы Указында билгеләнгән 2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәрге перспективага Россия Федерациясе үсешенең ике илкүләм максаты:<br>«Тотрыклы һәм динамикалы икътисад»;<br>макроикътисадый тотрыклылык, эшсезлек түбән дәрәҗәдә сакланганда һәм структур эшсезлек дәрәҗәсе кимегәндә илнең тулаем эчке продуктының үсеш темпын уртача дөньякүләм продукттан югарырак дәрәҗәдә тәэмин итү һәм, 2030 елдан да соңга калмыйча, сатып алу сәләте паритеты буенча исәпләнгән тулаем эчке продукт күләме буенча, шул исәптән хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү исәбеннән дөньяда дүртенче урынга чыгу;<br>2024 – 2030 елларда кече һәм урта эшкуарлык субъектының бер хезмәткәренә керемнең реаль үсешен тулаем эчке продукт үсешенә караганда 1,2 тапкырга югарырак тәэмин итү;<br>«Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит»:<br>гражданнарны 2030 елга бер кешегә кимендә 33 кв.метр һәм 2036 елга кимендә 38 кв.метр мәйданлы торак белән торак белән тәэмин итү;<br>2) Стратегия-2030 белән билгеләнгән дүрт стратегик максат:<br>дәүләт мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт белән идарә итү буенча югары квалификацияле белгечләр рәвешендә Татарстан Республикасының кеше капиталын туплау;<br>балансы территориаль-пространство үсеше;<br>җир ресурсларыннан файдалануның югары нәтиҗәлелеген тәэмин итү;<br>Татарстан Республикасында дәүләт, хосусый һәм дәүләт-хосусый институтларның балансы системасын булдыру, конкурентлыкка сәләтле кластерларны, эшкуарлыкны (кече һәм урта бизнесны), эчке территориаль үсешне тотрыклы үстерү;<br>3) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Пространство мәгълүматларының илкүләм системасы» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2021 елның 1 декабрендәге 2148 номерлы карары белән расланган «Пространство мәгълүматларының илкүләм системасы» Россия Федерациясе дәүләт программасының максатлары |

## 2. Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткеч дәрәҗәсе | Арту / кимү билгесе | Үлчәү берәмлеге (Үлчәү берәмлекләре гомумроссия классификаторы буенча) | База күрсәткече | | Еллар буенча күрсәткеч зурлыгы | | | | Документ | Күрсәткечкә ирешкән өчен җаваплы | Илкүләм максатлар, Стратегия-2030 максатлары күрсәткечләре белән бәйләнеш | Муниципаль берәмлектә гамәлгә ашыру билгесе | Мәгълүмат системасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | күрсәткече | елы | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| 1. | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең, аның керемлелеген һәм сакланышын максималь нәтиҗәлелеген тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | Хисап елы башына дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен реализацияләүдән һәм алардан файдаланудан алынган керемнәр өлешендә бюджет биремен үтәү | Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – ДП) | арта бара торган | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмәне раслау турында» 2024 ел, 15 март, 151 нче карары | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | макроикътисадый тотрыклылык, эшсезлек түбән дәрәҗәдә саклангында һәм структур эшсезлек дәрәҗәсе кимегәндә илнең тулаем эчке продуктының үсеш темпын уртача дөньякүләм продукттан югарырак дәрәҗәдә тәэмин итү һәм, 2030 елдан да соңга калмыйча, сатып алу сәләте паритеты буенча исәпләнгән тулаем эчке продукт күләме буенча, шул исәптән хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү исәбеннән дөньяда дүртенче урынга чыгу | юк | Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2. | Хисап елы башына җир кишәрлекләрен түләүсез алу өчен исәпкә баскан Татарстан Республикасы күпбалалы гаиләләренең гомуми санында җир кишәрлекләрен түләүсез алган Татарстан Республикасы күпбалалы гаиләләре өлеше | ДП | арта бара торган | процент | 66,5 | 2023 | 69 | 67 | 67 | 67 | «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның 16 статьясына һәм Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 14 июнендәге 138-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмәләрне раслау турында» 2024 ел, 15 март, 151 нче карары | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | гражданнарны 2030 елга бер кешегә кимендә 33 кв.метр һәм 2036 елга кимендә 38 кв.метр мәйданлы торак белән торак белән тәэмин итү; | әйе | Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контуры «Күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен бирү» электрон сервисында урнаштырылган җир кишәрлекләрен бирүгә гаризалар реестры |
| 1.3. | Муниципаль милек хокукына ия дип танылган, файдаланылмый торган җир өлешләренең өлеше | ДП | арта бара торган | процент | 69,0 | 2023 | 69,3 | 69,8 | 70,3 | 70,8 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмәне раслау турында» 2024 ел, 15 март, 151 нче карары | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | макроикътисадый тотрыклылык, эшсезлек түбән дәрәҗәдә саклангандa һәм структур эшсезлек дәрәҗәсе кимегәндә илнең тулаем эчке продуктының үсеш темпын уртача дөньякүләм продукттан югарырак дәрәҗәдә тәэмин итү һәм, 2030 елдан да соңга | әйе | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирләр һәм |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | калмыйча, сатып алу сәләте паритеты буенча исәпләнгән тулаем эчке продукт күләме буенча, шул исәптән хезмәт житештерүчәнлеген үстерү исәбеннән дөньяда дүртенче урынга чыгу; | | мөлкәт белән идарә итү буенча хисаплылык рәвешләре турында» 2020 елның 2 июнендәге 1779-б номерлы боерыгы нигезендә бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре күрсәткечләре |
| 1.4. | Финанс-хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләре гомуми санында Татарстан Республикасының зыянга эшләүче дәүләт унитар предприятиеләре өлеше | ДП | арта бара торган | процент | 11,0 | 2023 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмәне раслау турында» 2024 ел, 15 март, 151 нче карары | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | макроикътисадый тотрыклылык, эшсезлек түбән дәрәҗәдә саклангана һәм структур эшсезлек дәрәҗәсе кимегәндә илнең тулаем эчке продуктының үсеш темпын уртача дөньякүләм продукттан югарырак дәрәҗәдә тәэмин итү һәм, 2030 елдан да соңга калмыйча, сатып алу сәләте паритеты буенча исәпләнгән тулаем эчке продукт күләме буенча, шул исәптән хезмәт житеш- | юк | Федераль салым хезмәтенең бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы буенча дәүләт мәгълүмат ресурсы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | терүчәнлеген үстерү исәбеннән дөньяда дүртенче урынга чыгу; | | |
| 1.5. | Дәүләт унитар предприятиеләре һәм Татарстан Республикасы өлеше 50 процент-тан артык булган акционерлык җәм-гыятьләре бөлген-леге (банкрот-лыгы) турындагы эшләр буенча арбитраж идарәче-ләрнең чыгым-нарын компенса-цияләү өчен Татарстан Респуб-ликасы бюджетын-нан түләнгән сумма | ДП | кими бара торган | мең сум | 0,0 | 2023 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | Татарстан Респуб-ликасы Министр-лар Кабинетының «2024 – 2026 ел-ларга республика башкарма хаки-мият органнарына, Татарстан Рес-публикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмәне раслау турында» 2024 ел, 15 март, 151 нче карары | Татар-стан Респуб-ликасы Җир һәм мөлкәт мөнәсә-бәтләре мини-стрлы-гы | макроикътисадый тотрыклылык, эшсезлек түбән дәрәҗәдә саклан-ганда һәм структур эшсезлек дәрәҗәсе кимегәндә илнең тулаем эчке про-дуктының үсеш темпын уртача дөньякүләм про-дукттан югарырак дәрәҗәдә тәэмин итү һәм, 2030 ел-дан да соңга калмыйча, сатып алу сәләте пари-теты буенча исәп-ләнгән тулаем эчке продукт күләме буенча, шул исәп-тән хезмәт җитеш-терүчәнлеген үстерү исәбеннән дөньяда дүртенче урынга чыгу; | юк | Федераль казначы-лыкның Татарстан Республи-касы буенча идарәсе мәгълүмат-лары |
| 1.6. | Кече һәм урта эшкуарлык субъ-ектларына бирү өчен билгеләнгән дәүләт мөлкәте исемлегендәге объектлар саны | ДП | арта бара торган | шартлы берәм-лек | 117 | 2023 | 129 | 129 | 129 | 129 | «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорациясе» акционерлык җәмгыяте һәм Идел буе федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъ-ектлары арасын-дагы киңәшмәнең 2019 елның 26 сентябрендәге | Татар-стан Респуб-ликасы Җир һәм мөлкәт мөнәсә-бәтләре мини-стрлы-гы | 2024 – 2030 елларда кече һәм урта эшкуарлык субъектының бер хезмәткәренә керемнең реаль үсешен тулаем эчке продукт үсе-шенә караганда 1,2 тапкырга юга-рырак тәэмин итү | юк | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | 01-ПФО номерлы беркетмәсе | | | | |
| 1.7. | Комплекслы кадастр эшләрен үткәрү буенча планлаштырылган чараларның гомуми күләмендә комплекслы кадастр эшләрен үткәрү буенча башкарылган чаралар өлеше | ДП | арта бара торган | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | гражданнарны 2030 елга бер кешегә кимендә 33 кв.метр һәм 2036 елга кимендә 38 кв.метр мәйданлы торак белән торак белән тәэмин итү | юк | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайты mzio.tatarstan.ru |

## 3. 2024 елда Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләренә ирешү планы

| Т/с | Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары / күрсәткечләре | Күрсәткеч дәрәҗәсе | Үлчәү берәмлеге (Үлчәү берәмлекләре гомумроссия классификаторы буенча) | Айлар буенча план күрсәткечләре | | | | | | | | | | | 2024 ел ахырына |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | гыйнвар | февраль | март | апрель | май | июнь | июль | август | сентябрь | октябрь | ноябрь | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| 1. | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең, аның керемлелеген һәм сакланышын максималь нәтиҗәлелеген тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | Хисап елы башына дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен реализацияләүдән һәм алардан файдаланудан алынган керемнәр өлешендә бюджет биремен үтәү | ДП | процент | 5,0 | 8,0 | 12,0 | 20,0 | 30,0 | 40,0 | 50,0 | 60,0 | 80,0 | 85,0 | 90,0 | 100,0 |
| 1.2. | Хисап елы башына җир кишәрлекләрен түләүсез алу өчен исәпкә баскан Татарстан Республикасы күпбалалы гаиләләренең гомуми санында җир кишәрлекләрен түләүсез алган Татарстан Республикасының күпбалалы гаиләләре өлеше | ДП | процент | - | - | 66,4 | - | - | 67,2 | - | - | 68,4 | - | - | 69,0 |
| 1.3. | Муниципаль милек хокукына ия дип танылган, файдаланылмый торган җир өлешләренең өлеше | ДП | процент | - | - | 68,9 | - | - | 69,0 | - | - | 69,1 | - | - | 69,3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.4. | Финанс-хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләре гомуми санында Татарстан Республикасының зыянга эшләүче дәүләт унитар предприятиеләре өлеше | ДП | процент | - | - | 44,4 | - | - | 33,3 | - | - | 50,0 | - | - | 50,0 |
| 1.5. | Татарстан Республикасы өлеше 50 процենттан артык булган дәүләт унитар предприятиеләренең һәм акционерлык җәмгыятьләренең бөлгенлеге (банкротлыгы) турындагы эшләрдә арбитраж идарәчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан түләнгән сумма | ДП | мең сум | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| 1.6. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән дәүләт мөлкәте исемлегендәге объектлар саны | ДП | шартлы берәмлек | 117 | 117 | 117 | 117 | 117 | 117 | 117 | 117 | 117 | 129 | 129 | 129 |
| 1.7. | Комплекслы кадастр эшләрен үткәрү буенча планлаштырылган чараларның гомуми күләмендә комплекслы кадастр эшләрен үткәрү буенча башкарылган чаралар өлеше | ДП | процент | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 100,0 |

## 4. Татарстан Республикасы дәүләт программасы структурасы

